ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НАРАТЛЫ-КИЧУСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ НАРАТЛЫ-КИЧУ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

423714,Республика Татарстан
Мензелинский район, с.Наратлы-Кичуского, ул.
Центральная , дом 2

423714, Татарстан Республикасы,
Минзәлә районы, Наратлы-Кичу авылы, Центральный
урамы, 2

телефон: (85555)3-51-96. E-mail Narat.K@tatar.ru


# К А Р А Р

«10 май, 2018ел. Наратлы- Кичү авылы № 12

## Минзәлә муниципаль районының Наратлы- Кичү авыл җирлеге территориясендә янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итүгә җәмәгать контролен оештыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә, халыкның һәм гражданнарның муниципаль берәмлек территориясендәге янгыннардан саклануын тәэмин итү максатларында,

**К А Р А Р Ч Ы Г А Р А М :**

1. Минзәлә муниципаль районының Наратлы- Кичү авыл җирлеге территориясендә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүгә җәмәгать контролен оештыру турындагы нигезләмәне расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм районның рәсми сайтында бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Минзәлә муниципаль районының**
**Наратлы-Кичү авыл җирлеге**
**Башкарма комитеты җитәкчесе** **Ф. Х. Минһаҗев**

1 нче кушымта
Карар
«10» май 2018ел № 12

Нигезләмә
Минзәлә муниципаль районының Наратлы- Кичү авыл җирлеге территориясендә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүгә җәмәгать контролен оештыру турында

1. Авыл җирлекләре территориясендә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү максатларында җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә, җәмәгать контролен оештыру турында карар кабул итә.
2. Минзәлә муниципаль районы Наратлы-Кичү авыл җирлегенең җәмәгать контроленең төп бурычы - янгыннарны профилактикалауны, аларны сүндерүне һәм һәлакәттән коткару эшләрен башкаруны күзәтүдән гыйбарәт.
3. Җәмәгать контроле органнарына түбәндәгеләр керә:
- авыл Советы депутатлары;
- җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты;
- оешмалар хезмәткәрләре һәм гражданнар.
4. Җәмәгать контроле вәкилләре үз эшчәнлекләрендә Россия Федерациясе Конституциясе, федераль конституция законнары, федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәте, Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының норматив хокукый актлары һәм билгеләнгән тәртиптә расланган Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, шулай ук әлеге Нигезләмә белән таяна.
5. Җәмәгать контроле вәкилләре үз компетенцияләре кысаларында:
- җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары һәм гражданнар тарафыннан янгын куркынычсызлыгы таләпләрен тәэмин итүгә күзәтүне оештыра һәм гамәлгә ашыра;
- янгыннарның сәбәпләрен ачыклауда катнашалар;
- булган документларны анализлау нигезендә тикшерүләр башкару буенча гражданнарның оешмаларын һәм йорт биләмәләрен билгелиләр;
- федераль башкарма хакимият органнары, шул исәптән дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, җирле үзидарә органнары белән хезмәттәшлек итәләр.
6. Җәмәгать контроле вәкилләре составы гражданнарның гомуми җыелышында (референдумда, җыенында) гади күпчелек тавыш белән аерым сайлана.
7. Җәмәгать контроле вәкилләре гражданнарның гомуми җыелышында (референдумда, җыенында) расланган хокукларга ия булалар.

8. Җәмәгать контроле вәкилләре түбәндәгеләргә бурычлы:
- янгыннарны профилактикалауны, аларны сүндерүне һәм җирлек чикләрендә һәлакәттән коткару эшләрен уздыруны оештыруны үз вакытында күзәтүне гамәлгә ашырырга;
- Россия Федерациясе законнарын, оешмаларның һәм гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәргә;
- җирле үзидарәнең вазыйфаи затларын һәм тикшерүләр нәтиҗәләре белән гражданнарны таныштырырга;
- коммерция һәм закон белән саклана торган башка серне сакларга.
9. Җәмәгать контроле вәкилләре тиешенчә үтәмәгән яисә үз бурычларыннан читләшкән өчен җәмәгать контроле составыннан чыгарылырга мөмкин.